ЗУР СӘРДЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

«28» апрель 2022 ел № 11

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарә сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозу җитди булмаса, җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законнар, «Муниципаль вазыйфа яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын яисә җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы, «Муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» 2017 елның 19 июлендәге 57-ТРЗ номерлы законнары, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Зур Сәрдек авыл җирлеге Уставы нигезендә Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарә сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозу җитди булмаса, җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибен расларга (кушымта).

Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә

керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Зур Сәрдек авыл җирлеге территориясендә мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән игълан итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

Зур Сәрдек авыл
җирлеге башлыгы Ф.М.Фаттахов

Кукмара муниципаль районының Зур Сәрдек авыл җирлеге Советының 2022 елның 28 апрелендәге 11 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарә сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозу җитди булмаса, җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарә сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына (алга таба – муниципаль вазыйфаны биләүче зат) үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр (алга таба – керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр) биргән өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозу җитди булмаса, җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итүнең әлеге тәртибе карар кабул итү процедурасын регламентлый (алга таба – җаваплылык чарасы).

2. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы $7^{3-1}$ өлеше нигезендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән затларга карата түбәндәге җаваплылык чаралары кулланыла:

1) кисәтү;

2) депутатны, Зур Сәрдек авыл җирлеге җирле үзидарә сайланулы органы әгъзасын, аның вәкаләтләре срогы тәмамланганчы, Зур Сәрдек авыл җирлеге Советында, Зур Сәрдек авыл җирлеге җирле үзидарәсенең сайланулы органында вазыйфалар биләү хокукыннан мәхрүм итеп, Зур Сәрдек авыл җирлеге Советында, Зур Сәрдек авыл җирлеге җирле үзидарә сайланулы органында вазыйфа биләүдән азат итү;

3) аның вәкаләтләре вакыты беткәнчегә кадәр даими нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итеп, даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан азат итү;

4) Зур Сәрдек авыл җирлеге Советында, Зур Сәрдек авыл җирлеге җирле үзидарә сайланулы органында аның вәкаләтләре срогы тәмамланганчы вазыйфаларны биләүне тыю;

5) вәкаләтләре срогы тәмамланганчы даими нигездә вәкаләтләрен үтәүне тыю.

3. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга карата әлеге Тәртипнең 2 пунктында санап үтелгән җаваплылык чараларының берсен куллану турындагы мәсьәлә Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы (алга таба – Совет) тарафыннан карала.

Әлеге мәсьәләне карау өчен «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы $7^3$ өлешендә каралган Татарстан Республикасы Президентының муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чараларын куллану турындагы гаризасы нигез булып тора.

4. Җаваплылык чараларын куллану турында Татарстан Республикасы Президенты гаризасы Совет тарафыннан аның кергән көненнән өч айдан да соңга калмыйча карала.

5. Совет муниципаль вазыйфаны биләүче затка, аңа карата күрсәтелгән мәсьәләне карау датасына кадәр биш эш көненнән дә ким булмаган вакыт эчендә язма рәвештә җаваплылык чараларын куллану турындагы мәсьәләне карау турында хәбәр итә.

Совет утырышы урыны һәм вакыты турында хәбәр ителгән муниципаль вазыйфаны биләүче затның килмәве Татарстан Республикасы Президентының җаваплылык чараларын куллану турындагы гаризасын карауга комачауламый.

6. Муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чараларын куллану турында Татарстан Республикасы Президенты гаризасы Совет утырышында Зур Сәрдек авыл җирлеге Советының 23.12.2005 15 номерлы карары белән расланган Регламентта (алга таба – Регламент) билгеләнгән тәртиптә карала .

Күрсәтелгән мәсьәләне караганда муниципаль вазыйфаны биләүче затка тапшырылган мәгълүматлар буенча аңлатмалар бирү мөмкинлеге бирелергә тиеш.

Муниципаль вазыйфа биләүче затка җаваплылык чараларының берсе куллану турындагы мәсьәләне караганда, депутатлар тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу буенча таләпләр үтәлергә тиеш. Совет утырышында рәислек итүче мәнфәгатьләр каршылыгының барлыкка килү мөмкинлеге турында хәбәр итәргә кирәклекне депутатларга тәкъдим итәргә тиеш.

Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салу максатларында, мәнфәгатьләр конфликты яклы депутат карар кабул итүдән рәислек итүче тарафыннан читләштерелә.

7. Татарстан Республикасы Президенты гаризасын карау нәтиҗәләре буенча муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чараларын куллану яисә җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турында карар кабул ителә.

Әлеге карар Регламентта билгеләнгән тәртиптә кабул ителә.

Татарстан Республикасы Президентының аңа карата гаризасы кергән депутат тавыш бирүдә катнашмый.

8. Җаваплылык чараларын куллану турындагы карар гаделлек, төрлелек, пропорциональлек һәм котылгысызлык принциплары нигезендә кылынган коррупцион хокук бозу характерын, аның авырлыгын, ул кылынган хәлләрне исәпкә алып, шулай ук муниципаль вазыйфаны биләүче зат тарафыннан үз вазыйфаи бурычларын (вәкаләтләрен) үтәүнең алдагы нәтиҗәләрен, шулай ук коррупциягә

каршы тору максатларында билгеләнгән башка чикләүләрне, тыюларны һәм бурычларны үтәвен исәпкә алып кабул ителә.

Хисап чорында керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат биргән өчен бары тик бер генә җаваплылык чарасы кулланылырга мөмкин.

9. Җаваплылык чараларын куллану турындагы карарда коррупциячел хокук бозуга күрсәтмә, муниципаль вазыйфаны биләүче зат тарафыннан бозылган норматив хокукый актларның нигезләмәләре, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә карарга шикаять белдерү хокукы булырга тиеш.

10. Җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карарда мондый баш тартуның дәлилләнгән нигезе булырга тиеш.

11. Җаваплылык чарасын куллану яисә җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карарның күчермәләре кабул ителгәннән соң биш эш көне эчендә муниципаль вазыйфа биләүче затка имза куйдырып тапшырыла яисә тапшыру турында хәбәрнамә белән почта аша җибәрелә, шулай ук Татарстан Республикасы Президентына җибәрелә.

Җаваплылык чарасын куллану турындагы карарны муниципаль вазыйфаны биләүче затка җиткерү мөмкин булмаса яки күрсәтелгән зат карарны кул куеп кабул итүдән баш тартса, башкарма комитеты сәркатибе (*җаваплы зат вазыйфасы)* җаваплылык чараларын куллану турындагы карар белән югарыда күрсәтелгән затның танышудан баш тартуы яисә аны әлеге хәбәрнамә белән таныштыру мөмкин булмавы хакында акт төзелә.

12. Җаваплылык чарасын куллану яисә җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карарга карата Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.